ПИЖМАРСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЫЖМАРА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«29» июнь 2022ел** **№ 49**

**Милеккә салым турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, "Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында" 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри физик затлар милкенә салым билгеләү һәм гамәлгә кертү.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

2.1. 0,1 % итеп:

- 2.4 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннарына;
- һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмаларына;

2.2. 0,2 % итеп:

- фатирларга, фатир өлешләренә;
-бүлмәгә;

2.3. 0,3 % итеп:

- торак йортларга, торак йорт өлешләренә;
- төзелеп бетмәгән төзелеш объектларына, әгәр мондый объектларның проектланучы билгеләнеше торак йорт булса;
- Бердәм күчемсез комплексларга, әгәр составына бер генә булса да торак йорт керсә;

2.4. әлеге Кодексның 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата, әлеге Кодексның 378.2 статьясындагы 10 пунктындагы икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата, шулай ук салым салу объектларына карата, аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына 2% итеп;

2.5. Башка салым салу объектларына карата 0,5%.

2.6.Ике фатирдан торган күп фатирлы йорттагы фатирга милек хокукы булган физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метрына салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә ташламалар билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламаларның суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукында пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектә катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Бу очракта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы аны исәпкә алмыйча исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый.

3. Пыжмара авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 ноябрендә кабул ителгән 111 номерлы «Милеккә салым турында» карары (9.11.2015 ел, №9, 28.04.2018 ел, №76 үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының http://baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру һәм Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге территориясендә урнаштырылган мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә кирәк.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Пыжмара авыл
җирлеге башлыгы        Р.Х.Заляев